وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаh арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№3 (146). 20 июль 2012 / 1-рамазан-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




Остазым ▷2◁

Мөселман мәгарифе парадигмасында ▷3-4◁

"Рамазан – мәрхәмәт ае" акциясе башланды ▷4◁





## ЯҢАЛЫКЛАР

**ТӨРМӘДӘ УТЫРУЧЫЛАР ӨЧЕН ИФТАР ОЕШТЫРЫЛАЧАК**

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе белән координация һәм хезмәттәшлек буенча бүлеге соңгы көннәрдә, изге Рамазан аена багышланган чараларны әзерләү максатыннан, төзәтү учреждениеләре башлыклары белән очрашты.

Әлеге бүлектә 10 июльдән ураза тотуга әзерлек алып барыла: төзәтү колонияләре өчен азык-төлек сатып алып җибәрелә.

**ТАТАРСТАН МӨФТИЕ "АЛЬ-РТВ" ТЕЛЕКАНАЛЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ ҺӘМ РЕДАКЦИОН СОВЕТЫ СОСТАВЫНА КЕРДЕ**

17 июль көнне Мәскәүдә мөселманнарга адресланган "Аль-РТВ" гомумроссия телевизион каналының Иҗтимагый советы утырышы үтте.

Җыелышта "Аль-РТВ" телеканалының ачылышына кагылышлы сораулар да каралып үтте, соңыннан "Мөселманнар өчен һәм мөселманнар турында гомумроссия телеканалы ачу турында меморандум" кабул ителде. Әлеге канал 2012 елның 19 августында – Ураза гаете көнне эшли башлаячак. Шулай ук яңа каналга редакцион совет әгъзалары сайланылды, шул исәптән Илдус хәзрәт Фәиз дә шулар арасында. ТР мөфтие "Аль-РТВ" Иҗтимагый советы составына да керде.

Телеканал башка телевидениеләр принцибы буенча эшләячәк, шулай да мөселман аудиториясенең үзенчәлеге һәм традицияләре дә исәпкә алыначак. Каналның җитәкчелеге тарихи-дини һәм милли-мәдәни агарту эшчәнлеге алып баруны төп максат итеп куя.

**«ХӘЛӘЛ» КОМИТЕТЫ РАМАЗАНДА ХӘЛӘЛ ДИП ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН РИЗЫКЛАРГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫРГА ЧАКЫРА**

Бүген Изге Рамазан ае башланды. Шул уңайдан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандартлары комитеты мөселманнарны "хәләл" дип тәкъдим ителгән ризыкларга аеруча игътибарлы булырга кирәклекне җиткерә.

Ел да нәкъ менә Рамазан вакытында хәләл товарлар белән кызыксыну арта. Сәүдәгәрләр, җитештерүчеләр шушы күренештән файда күреп калу максаты белән, сатып алучыларны үз товарларының хәләл булуына төрле юллар белән ышандырырга тырыша. Мәсәлән, ярлыкларга "ит пилмәне", "мөселманча", "татар пилмәне" кебек сүзләрне өстиләр. Бу сүзләр әле ризыкның чынлап та хәләл булуын расламый.

*"Хәләл" стандартлар Комитеты тикшерүен узган һәм комитет реестерына кертелгән оешмалар җитештергән ризыкларның хәләл булуы шик тудырмый. Комитетта сертификация узган предприятиеләр исемлеге белән www.halalrt.com сайтыннан танышырга мөмкин.*

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!**

**Һәр айның 24 нче числосына кадәр почтага барып "Дин вә мәгыйшәт" газетасына язылсагыз, ул сезгә киләсе ай башыннан килә башлаячак.**

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт ФӘИЗнең Рамазан ае башлану уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

**Мөхтәрәм дин кардәшләребез!**

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, 20 июльдә мөселманнар өчен иң кадерле ай – Рамазан ае башланды. Бу айда Аллаһы Тәгалә безгә туры юл күрсәтүче Коръәни-Кәримне иңдергән, шуңа да Рамазан ае – Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән яктыртылган аеруча мөһим ай. Бу айда мөселманнарга ураза тоту фарыз ителгән. Коръәндә: "Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган ап-ачык дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр. Шуңа күрә, шушы айга килеп ирешкәннәр ураза тотсын. Хаста булганнар яки сәфәрдәгеләр (тотылмаган көннәре хисабынча) башка көннәрне ураза тотар. Аллаһ сезгә җиңеллек тели, кыенлык теләми. Санаулы (ураза) көннәрне тәмам итеп, сезгә тугры юл күрсәткәне өчен, Аллаһны олылагыз, бәлки сез шөкер итүчеләрдән булырсыз?", – дип әйтелә "Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 185 нче аятендә.

Рамазан аенда ураза тоту – ислам диненең биш баганасының берсе, димәк, авыру булмаган һәр мөселман өчен фарыз гамәл. Ураза тоту таң ату вакыты алдыннан алып, кояш баеганчыга кадәр ашау-эчүдән, җенси мөнәсәбәтләрдән тыелып торуны аңлата. Шулай ук уразадагы кеше рухи калебенә һәм ниятләренә зарар китерүче начар сүзләрдән, уй-фикерләрдән, ялганнан, бәхәсләрдән һәм башка зыянлы нәрсәләрдән читтә торырга тиеш. Гыйбадәт кылуда сабырлык, фәкыйрьләргә карата шәфкатьлелек күрсәтеп, нәфесебезне тыеп тора алсак иде.

Рамазан аенда тоткан уразаның иң зур бүләге – гөнаһларыбызның кичерелүе. Моңар ихлас теләк һәм омтылышларыбыз белән ирешеп була. Аллаһы Тәгалә илчесенең (сгв) Сөннәтендә болай диелгән: "Рамазан аенда, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешергә теләп, чын күңелдән ураза тоткан кешенең элек кылган гөнаһлары гафу ителәчәк".

Рамазан ае фазыйләтләренең берсе булып Кадер кичәсе тора. Бу кичәнең кыйммәте мең айдан да өстенрәк. Нәкъ менә бу кичәдә Изге Коръән иңдерелгән, шуңа күрә бу кичтә бихисап санда фәрештәләр мөэминнәргә якынаеп җиргә төшә. Кадер кичәсендә кылган изге гамәлләребезнең әҗер-саваплары зурдан булыр.

Рамазан аеның фазыйләтләре бик күп, шуңа да бу айда без аеруча тырышлык белән гыйбадәт кылсак, аның савабын, рухи кыйммәтен ныграк тоярбыз. Ярдәмгә мохтаҗлар турында онытмыйк, чөнки алар безнең алда түгел, ә без аларга Ахирәттә Аллаһы Тәгалә ризалыгына ирешү мөмкинлеген бирүләре өчен бурычлы.

Әлеге изге айны барыбызга гыйбадәттә уздырырга язсын, төннәрне Аллаһка зекер кылып, Коръән укып һәм якыннарыбызны сөендереп үткәрик. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә барыбызга да көч һәм сабырлык бирсен! Тоткан уразаларыбызны, кылган изге гамәлгыйбадәтләребезне, догаларыбызны, укылган тәравих намазларыбызны кабуллардан кылса иде. Әмин!


***Үзәкләшкән дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# Хаҗ буенча квоталар дини оешмалар арасында бүленгән

***18 июль көнне Татарстан мөфтиятендә узган матбугат очрашуында ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз Татарстанда 2012 елда хаҗ оештыру белән "Хезмәт тур" һәм "Татар эшмәкәрлек дөньясы" ҖЧҖ туристик операторлары шөгыльләнәчәген хәбәр итте.***

Ул хаҗ кылу өчен билгеләнгән квоталарның үзәкләшкән дини оешмаларга гына бирелүен аңлатып үтте. 2012 елның апрелендә Хаҗ буенча совет утырышында квоталар Россиянең дини оешмалары арасында бүленгән. Шулай ук 2012 елда хаҗны оештыру белән шөгыльләнүче туроператорлар да билгеләнгән. Татарстанда бу - "Хезмәт тур" һәм "ДУМ РТ Хадж" программасы белән "Татар эшмәкәрлек дөньясы" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.

Башка коммерция компанияләре мөселманнарның диния нәзарәтләре каршында аккредитацияләнгән туроператорлар белән агентлык килешүләре төзергә тиеш. Шуңа күрә хаҗ кылырга теләүчеләр турфирмага документларын тапшырган вакытта бу оешманың квоталары бармы-юкмы икәнлеге турында белешергә тиеш. Әгәр оешманың квотасы булмаса, мөселманнарның диния нәзарәтләре каршында рәсми аккредитацияләнгән компаниягә мөрәҗәгать итәргә кирәк.



# ВӘЛИУЛЛА ХӘЗРӘТнең вафаты уңаеннан Татарстан мөселманнары кайгы уртаклаша

**19 июль көнне киң танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе Вәлиулла хәзрәт Якупов фаҗигале төстә вафат булды. Вәлиулла хәзрәтнең фаҗигале үлеме – Россия, Татарстан өммәте өчен зур югалту. Хәзрәтнең актив һәм күпкырлы эшчәнлеге Ислам динен торгызуда, аны үстерүдә зур роль уйнады.**



Ул чорыбызның тирән белемле мәгърифәтчесе, һәрнәрсәдән хәбәрдар тынгысыз әйдәп баручысы һәм республикабызны дини-мәдәни алгарышка илтүчесе булды. Күп гасырлар дәвамында халкыбызның горурлыгы булган традицион исламны яклады, танылган татар дин белгечләренең милли-дини мирасын җитди өйрәнде, аны бүгенге буынга җиткерде. Мәшһүр татар дин әһелләренең бай мирасы белән рухланып, аларның күркәм эшчәнлеген дәвам итте. Хәзрәт тормышка ашырган һәм башлангыч биргән изге эшләр бик озын исемлек тәшкил итә.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Вәлиулла хәзрәт Якуповның якыннарының тирән кайгысын уртаклаша. Без барыбыз да бу фаҗигаи хәлне зур авырлык белән күтәрәбез һәм Аллаһы Тәгаләгә догалар белән мөрәҗәгать итәбез.

Дин әһелләре Татарстанның барлык мәчетләрендә сабырлык күрсәтеп, Вәлиулла хәзрәтнең урыны җәннәт түрләрендә булсын дип догалар кыла.

## БЕЛЕШМӘ

**1963 елның 4 сентябрендә** Башкортстан Республикасының Дмитриевка авылында дөньяга килгән **Вәлиулла ЯКУПОВ** - йөздән артык китап авторы, "Иман" ислам мәдәнияте үзәгенә нигез салучы. "Иман" нәшриятының мөхәррире, шулай ук 1993 елдан башлап "Мөхәммәдия" мөселман мәдрәсәсенә яңа сулыш өреп җибәрүче. Аның җитәкчелегендә XVIII йөзнең тарихи һәйкәле - Апанай мәчете торгызылды.

В.Якупов - тарих фәннәре кандидаты, Апанай мәчете имам-хатыйбы, Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы әгъзасы, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире, РФ Юстиция министрлыгының Дәүләти дини экспертиза үткәрү буенча Эксперт советы рәисе урынбасары, РФ Тышкы эшләр министрлыгының мөселман оешмалары белән бәйләнеше буенча Консультатив совет әгъзасы, шулай ук ТР Фәннәр академиясенең Ислами тикшерүләр үзәге фәнни хезмәткәре.

# ОСТАЗЫМ

БЕЗНЕҢ ЮБИЛЯР


***Мәчет-мәдрәсәләре саны буенча Казаныбыз - Россиядә беренчелекне тотучы шәһәр. Бүгенге көндә Мәдинә мәчете имам-хатыйбы Гыйльмулла Зәкиулла улы Хәлиуллин исә - башкалабызда иң өлкән мулла. Аны ХХ гасыр белән ХХI гасырны тоташтырган күпер дисәк тә ялгышмабыз. Гасырлар кисешкән дәвердә, дин-исламга хезмәт итәргә алынып, күпкырлы эшләр җәелдергән Гыйльмулла хәзрәткә бу көннәрдә 80 яшь тула. Имам-хатыйпның гомер бәйрәменә багышлап, "Хәтер дисбесе" исемле китап дөнья күрде. Журналист Вәсилә Рәхимова оештырган һәм гамәлгә куйган әлеге китаптан бер өзек тәкъдим итәбез.***

***"Адәм баласы үлсә, аңардан гамәл киселә. Әмма изгелек, әҗер-савап килеп торсын өчен, ул өч юл ачып калдыра ала. Беренчесе - кешеләр бушлай файдаланыр өчен мәчет, мәдрәсә, шифаханә, мосафирханә, күпер төзетү булып, кое, чишмәләр казу, җимеш агачлары утырту кебек саваплы гамәлләр дә шунда керә. Икенчесе - гыйлем алу булып, шул гыйлеменнән әсәр калдыруга нигезләнәдер. Өченчесе - изге балалар үстереп, шул балаларының дога кылуларына ирешүдер".***

**Хәдис**

Гыйльмулла абый белән тәүге танышуыбыз 1994 елның көзендә булды дип хәтерлим. Дин кардәшенең дин кардәшенә сүз катуы, сөйләшер сүз табуы - гадәти күренеш. Без дә җиңел таныштык, телефоннар алышып, күрешкән вакытларда җылы әңгәмәләр кора идек.

Күпмедер вакыт узгач, яңа танышым шалтырата. Үзенең Танкодромда мәчет төзү хыялы белән йөрүен уртаклаша. Шул сөйләшүдән соң Гыйльмулла абый муеннан эшкә чумды: бәйтуллаh төзү белән бәйле оештыру-аңлатулар эчендә бөтерелде. Мәчет төзү өчен җир алулар, мәхәллә оештырулар, халыкны ризалатып, дингә мәхәббәтен уятып, төзелеш башлаулары - үзе бер китап чыгарырлык хикмәтле хәлләр иде.




Бер кечкенә генә эпизодны искә алам. Урманчылардан "Мәчет бурасы әзер, килеп алыгыз!" дигән хәбәр килде. Тышта күз ачкысыз буран. Гыйльмулла абый җыенышмы-җыена. Без хәзрәтне юлга чыкмаска үгетлибез. "И-и-и балалар! Мине Аллаһы Тәгалә йөртә бит. Мин аңарга тапшырып чыгып китәм. Изге эштә йөрүчене үзе саклый, үзе җиңеллеген бирә", - ди. Шул вакытларны искә төшерсәм, күңелләрем тула. Тәвәккәлләп чыгып китте иртәнге сәгать өчтә. Йокыны исәпләп тормый ул. Кичке уннарда төялеп, исән-сау кайтып керделәр. Без монда көтеп тордык. Менә Аллаһы Тәгаләгә тапшырып чыгып китүнең хикмәтләре!

Аллага шөкер, мин дә бик теләп тартылдым бу эшкә. Кулымнан килгән ярдәмемне күрсәттем. Гел аралашып, киңәшләшеп тора торган булдык. Гыйльмулла абыйдан Аллаһы Тәгаләдән килгән бер имани көч, рәхәтлек бирә торган җылылык сирпелә. Мин шуны тоям, шуңа тартылам. Әтиебез яшьли дөнья куйды. Гыйльмулла абыйны танышканнан бирле әти урынында тоям. Бөтен эч серләремне, әни белән, хатын белән уртаклашып булмый торган серләрне хәзрәткә сөйли торган булдым. Менә шул 1994 елдан салынган дуслык бүгенгәчә дәвам итә. Әлхәмделилләһ, хәзрәттән күп нәрсәгә өйрәндем, шулай ук матур, дөрес итеп яшәргә дә. Аны "минем остазым" дип, авызымны тутырып әйтә алам. Тормыш дәверендә төрле чаклар булды. Ул һәр чакта бик миһербанлы, ярдәмчел, кеше өчен кайгыра торган остаз була белде. Кешенең тышкы кыяфәтенә карап түгел, эчке халәтен сизеп, күңел иләге аша уздырып ярдәм итүче зат дип беләм мин аны.

Мулла, имам булу ягыннан карасак, чын ихласы, Аллаһы Тәгалә ризалыгын алыйм дип, теше-тырнагы белән тырышып хезмәт итүче ул. Гыйльмулла хәзрәтнең мактауларга, дөнья байлыкларына исе китми. Имам вазифасына кермәгән, берәү дә кушмаган, сорамаган күпме башлангычларга үзе юл ярып, күпме матур эшләргә алынды. Ул һаман да бәрәкәтле гомер юлында. Казанда Мәдинә мәчете һәм мәдрәсә (Курчатов ур., 4а), шунда ук "Бәрәкәт" чишмәсе, мәчет ишегалдында - җимеш агачлары, гүзәллеккә мәдхия укучы чәчәкләр, матурлык, сафлык биреп торучы ак һәм зәңгәр чыршылар, ул капка-коймаларының затлылыгы! Берсе дә "әйдә ярар" дип түгел, халыкны үзенә тартып торырлык булсын, озак елларга хезмәт итсен дигән нияттән булдырылган.

Буа районының Аксу, Бик-Үти, Ташкичү авылларында һәм Буа шәһәренең яңа микрорайонында Хаҗилар мәчете, Казаннан ерак түгел Васильево бистәсендә Ихлас мәчете. Барысы да Аллаһы Тәгалә ризалыгын өмет итеп башкарган эш-гамәлләре. Төзелә торган мәчетләргә ярдәм итүен, туган авылындагы мәчетне җылыту өчен, ничә еллар инде пенсиясеннән өлеш чыгаруын әйтеп тә торасы юк.

Мәдинә мәчете моңарчы бернинди коммерциягә тыгылмады, сәүдә нокталары ачып, алыш-биреш итмәде. Хәзрәтнең моңа үз карашы: дин эшендә акча эшләүне катнаштырырга ярамый. Мәчет сәүдә итү урыны түгел. Ихлас күңелеңнән дингә хезмәт итсәң, Аллаһы Тәгалә үзе бирә, үзе ача юлларын, ди ул. Чыннан да шулай. Мәчет гөрләп эшли. Кеше дә йөри, хәзрәтнең ихластан хезмәт итүен дә күрә, сәдакасын да бирә. Сәдака-хәйрияне халыкка бише белән кайтару юлларын белә хәзрәт. Мәчетебездә Рамазан ае буена ифтар мәҗлесләре уза, Корбан аенда - корбан ашлары, Мәүлид аенда - Коръән ашлары. Җомгага килүчеләрне һәр атнада диярлек кайнар пылау, сыйлы табын көтә.

Быел хәзрәтнең юбилей елы - аңа 80 яшь. Аллаһы Тәгалә аны көч-куәт, гайрәт һәм олы йөрәк белән бүләкләгән. Берәү булса, эшлисен эшләдем, әйдәгез егетләр, хәзер дилбегә сездә, төзегез, булдырыгыз, әҗер-савабы Кыяматкәчә барып торырлык изге эшләргә алыныгыз, дияр иде. Юк, бирешми әле олпат зат. Үзенең туган авылы Ташкичүдә матур итеп буа будырып, күпер салдыру, Биектау районының Ташсу һәм Питрәч районының Көек авылларын мәчетле итү хыялы белән йөгереп йөри. Гыйльмулла абый, булдыра алырсыңмы соң, дип сорыйм кайчакта. "И-и-и егетләр, мин эшләмим бит аны, Аллаһы Тәгалә ярдәм итә бит миңа. Мин Аллаһка таянам, ул ташламаса, ниятләгән эшне башкарып чыгуыңны сизми дә каласың", - ди. Хак сүзләр, ихлас сүзләр! Мисаллары, дәлилләре күз алдыбызда. Хәзрәтнең кая барса да сүзе үтә, һәркем белән сөйләшә белә. Аллаһы Тәгалә аңа менә шундый сәләт, олпатлык биргән. Аның җайлап, матур итеп әйткән гозеренә кеше "юк" дип әйтергә базмый.

Карап-карап йөрим дә, безнең хәзрәт әллә үз-үзенә "бүген Аллаһ юлында нинди изгелек эшләп була, нинди юмартлык күрсәтеп була?" дигән сорау куямы икән дигән нәтиҗәгә киләм. Бигрәкләр дә киң күңелле, юмарт бит! Быел кыш мөфтият белән Россия ислам университеты имамнарның квалификациясен күтәрү курслары оештырды. Һәр районнан 15-20 имам 10 көн Казанда укыды. Гыйльмулла хәзрәт һәр төркемне үзебезгә җомгага дәште. Намаздан соң табын көйләп кунак иттек, җылы әңгәмәләшү, аралашу булды. Казан мәчете, мәхәллә белән танышсыннар, ничек эшләвебезне үз күзләре белән күрсеннәр дигән нияттән алынды хәзрәт бу башлангычка. Фани дөньяның исәп-хисабына корылмаган әлеге чын ислами очрашудан, тәҗрибә уртаклашудан авыл имамнары канәгать калдылар, дин гыйлеменең тормышта ничек кулланылуына шаһит булдылар. Педагоглар теле белән әйтсәк, ачык дәрес бирде хәзрәт, гамәли үрнәк күрсәтте. Өстәп шуны әйтә алам: Гыйльмулла абыйның дингә хезмәт итүе, халык белән уртак тел табып эшләү рәвеше бүген мәдрәсәләрдә укучы шәкертләргә, булачак дин әһелләренә дә зур тәҗрибә мәктәбе, гамәли үрнәк була ала. Фәкать күңел житеп килергә, танышырга һәм өлкән хәзрәттән бәйнә-бәйнә сорашырга гына кирәк...

Үзем белгән дәвердән алсаң, Гыйльмулла абый - бүгенге көндә Казаныбызда күркәм, мөхтәрәм аксакал. Безнең өчен ул зур үрнәк тә, таяныр таяныч һәм диндәге ихласлыгы белән күңелләрне яулаган имам да.

**Сираҗетдин НӘБИЕВ,**
**Казандагы Мәдинә мәчете мәәзине**

# Хәләл җитештерү белән һәркем таныша ала

**Соңгы вакытта кошчылык фабрикалары хәләл продукция җитештерүгә күбрәк игътибар бирә башлады. Чөнки аңа ихтыяҗ бар. Әмма әле бер, әле икенче фабриканың продукциясенең хәләллеген шик астына алган хәбәрләр дә ешрак тарала. Моны үзара конкуренциянең бер элементы итеп карарга буладыр.**



Мин, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы "Хәләл" комитетының экспертиза бүлеге җитәкчесе буларак, бу уңайдан шуларны белдерер идем. Әгәр кемдер теге яки бу продукциянең хәләллеген шик астына ала икән, бүгенге көндә аның шәригать таләпләренә җавап бирүен-бирмәвен тикшерү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Моның өчен "Хәләл" комитетының яки җитештерүче предприятиенең сайтына керергә һәм җитештерү технологиясе белән якыннан танышырга була. Әйтик, мин моны "Чаллы-Бройлер" мисалында күрсәтергә телим. Ошбу җәмгыять тавык итеннән хәләл продукция җитештерү эшенә 2004 елны тотынды. Һәм аны 40 тонна күләмендә эшләп чыгарды. Былтыр бу сан 5650 тонна тәшкил итте. Ягъни үсеш 150 мәртәбә. "Чаллы-Бройлер"да хәләл тавык ите, 20 төргә якын колбасалар, делекатеслар, вакуум саклагычта ысланган ризыклар эшләп чыгарыла. Җәмгыять хәзерге вакытта хәләл продукция җитештерүнең масималь куәтенә чыкты. Аны алга таба күбәйтү өчен яңа куәтләр таләп ителә. Биредә бүгенге көннең иң яхшы технологияләре кулланыла, күп процесслар, шул исәптән температура режимы автоматлаштырылган, компьютерлаштырылган.

Шунысы да бик мөһим: фабриканың ишекләре "Хәләл" комитеты белгечләре өчен һәрвакыт ачык – пропускларыбыз бар, керәбез, тикшерәбез. Биредә хәләл продукция өчен чебиләр Аллаһ исемен әйтеп кулдан суела. Бу эш һәр көнне иртәнге 5 тулып 30 минутта башлана, иртәнге 8 гә кадәр дәвам итә. Җиһазларның чисталыгы берничә контроль аша уза. Сую линиясендә суючылардан тыш контролёрлар тора. Алар җаны чыгып бетмәгән тавыкларны читкә алып куялар. Җаннары тәмам чыкканнан соң гына аларны яңадан линиягә кайтаралар. Сую белән пешекләү арасы 3,5 минут вакытны үз эченә ала. Зуррак һәм хәллерәк чебешләр булганда алар бу вакыт эчендә җан биреп өлгермәскә дә мөмкин. Шуңа күрә һәрбер чебешкә кул белән капшап, тереклек сыйфатының бармы-юкмы икәнлеге тикшерелә. Бу эш җаннары чыгып бетмәгән тавыклар пешекли торган суда тончыгып үлмәсеннәр өчен башкарыла.

Шуны да әйтим, "Чаллы-Бройлер" бүгенге көндә хәләл җитештерү өчен кулдан суюны башкарган бердәнбер фабрика булып кала бирә. Күптән түгел Германиядән яңа җиһазлар тәкъдим итү буенча вәкил килде. Аны озатып йөрергә туры килде. "Чаллы-Бройлер"да булганнан соң, бу вәкил конвейерда кулдан чалуның беренче мәртәбә үз күзләре белән күргәнлеген җиткерде. Чөнки Европаның, Американың хәләл продукция җитештерүчеләре механик пычаклар кулланалар.

Узган елның 7 июлендә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы рәисе Рөстәм хәзрәт Батыр, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм республикабызның төбәк казыйлары "Чаллы-Бройлер" җәмгыятендә булып, хәләл продукция җитештерү һәм саклау технологияләре белән якыннан таныштылар. Аларның фикере бер булды: җәмгыятьтә җитештерелгән продукция тулысынча шәригать таләпләренә җавап бирә.

"Чаллы-Бройлер" һәр елны Казанда һәм Мәскәүдә уза торган "Хәләл-Экспо" күргәзмәләрендә актив катнашып килә. Быел да ул алардан дипломнар алып кайтты. Шуңа күрә фабриканы чит илләрдә дә торган саен күбрәк беләләр һәм уңай бәялиләр. (Укучы дөрес аңласын: минем ниятем "Чаллы-Бройлер" продукциясенә реклама ясау түгел. Фәкать бер фабрика үрнәгендә хәләл җитештерүне күрсәтәсем килә).

Бүгенге көндә сәүдәгә хәләл чебешләр "Приосколье"дан, "Турбаслы бройлерлары"ннан да килә. Алар өчен Мөфтиләр шурасы, Башкортостан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы "Хәләл" комитетлары җавап бирә. Мин үзебезнең Комитет карамагындагы фабрикалар буенча гына сүз алып барам. Болар – алда аталган җәмгыятьтән тыш, Питрәч, "Акаш" (Мари-Эль), "Равис" (Чиләбе өлкәсе) кошчылык фабрикалары. Аларда җитештерелгән хәләл продукция һәрвакыт контроль астында, бернинди дә шик тудырмый.

**Фоат хәзрәт МӨХӘММӘТОВ,**
**Үзәкләшкән дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы "Хәләл" комитетының экспертиза бүлеге җитәкчесе**

# ФАЙДАЛЫ ДА, КҮҢЕЛЛЕ ДӘ ЯЛ

**Яшь буынның әхлагын үстерү һәм ислам дине турындагы белемнәрен киңәйтү максатыннан Кукмара мәдрәсәсе каршында инде өч ел рәттән җәйге мөселман лагере оештырыла. Быел мондый лагерь 1 июльдән 11 июльгә кадәр эшләде. Биредә мәктәп яшендәге балалар дини белем дә үзләштерде, рәхәтләнеп ял да итте.**



Дини тәрбияне максат итеп куйган лагерьның эшчәнлеген кайберәүләр ничектер берьяклы, болки, ялыктыргыч итеп тә күз алдына китерә торгандыр. Әмма биредәге көн тәртибе белән танышып чыкканнан соң, моның алай түгел икәнлегенә ышанасың. Төрле догаларны, гарәп хәрефләрен, ислам әхлагы кагыйдәләрен өйрәнүдән тыш, балалар футбол кебек хәрәкәтле уеннарда, викториналарда һәм башка кызыклы бәйгеләрдә көч сынашты. Һәр төркем үзенең стенгазетасын ясады, дини рәсемнәр конкурсында да катнашты. Лагерьга йөрүче балалар эшләгән рәсемнәрдән мәдрәсәдә күргәзмә оештырылды.

Шунысы игътибарны җәлеп итте - балаларга уку һәм ял итү өчен мәдрәсә бинасында барлык шартлар да тудырылды: биредә зур, якты, зәвык белән бизәлгән уку бүлмәләре, китапханә, ашханә бар, бөтен җирдә чисталык, тәртип. Шуңа күрә дә мәдрәсәдә оештырыла торган лагерьда катнашырга теләүчеләр саны елдан-ел арта бара. "Кызганыч, быел теләге булган барлык балаларны да кабул итә алмадык - бу урыннар чикле булуы белән аңлатыла. Шунысы да бар: лагерь үткәрү күп чыгымнар белән бәйле. Шулай да бу эшне башкарырга Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм итә", - ди мәдрәсә мөдире Ришат хәзрәт Курамшин.

Быел лагерьда барлыгы сиксәнгә якын бала ял иткән. Аларны җиде төркемгә бүлеп, һәрберсенә җитәкчеләр билгеләгәннәр. Һәр төркем өчен, балаларның яшенә, әзерлегенә карап, дәресләр программасы төзелгән. Спорт уеннарында һәм мәдәни чараларда исә шәкертләр бергәләп катнашканнар. Шушы уен-чараларда һәм, әлбәттә инде, дәресләрдә күрсәтелгән активлыгына карап, укучыларга ниндидер сан куелган һәм мөһер сугылган "балл" дип аталучы кәгазьләр бирелгән. Сменаның ахыргы көнендә исә махсус "Ярминкә" оештырылган һәм һәр балага җыелган "балларына" күңеленә хуш килгән әйберләр - китаплар, уенчык-сувенирлар "сатып алырга" мөмкинлек туган.

Ата-аналар, әби-бабайлар катнашында үткән лагерьны ябу мәҗлесендә балалар бик күңелле чыгыш ясадылар: кемдер азан әйтте, кемдер намаз укып күрсәтте, шигырь сөйләүчеләр, дини эчтәлекле җыр башкаручылар да байтак иде. Кайбер төркемнәр исә әдәп-әхлак темасына театральләштерелгән тамашалар әзерләде. Кечкенәрәк яшьтәге "шәкертләр" чыгышы аеруча күңелле, хәтта сокланырлык иде.

Җыен ахырында төрле номинацияләр буенча җиңүчеләр билгеләнеп, балаларга бүләкләр тапшырылды. Әйтик, "Иң яхшы Коръән укучы", "Иң күп ятлаучы", "Иң яхшы спортчы", "Иң тәртипле шәкерт" кебек җитди номинацияләрдән тыш, "Ризыкны иң тиз ашап бетерүче", "Бер урында иң аз вакыт тыныч утырып тора алучы", "Төркемдә иң шаян шәкерт" кебек җиңүчеләр дә тәгаенләнеп, аларга да "шаяру призлары" бирелде. Гомумән, лагерьга килгән бер генә бала да бүләксез калмады. "Шук, шаян булганга да бүләк бирәләр икән дигән сылтау белән киләсе елга барысы да шаярмаса ярар иде", - дип елмайды соңыннан остазлары.

Әти-әниләр дә балаларының мөселман лагерена йөргәннәренә чиксез шат иде. "Озын җәйге каникул чорында балалар күп вакытларын урамда үткәрә. Мәчет-мәдрәсә каршында оештырылган укуларда, лагерьда катнашып, алар шактый кирәкле күп мәгълүмат туплый, рухи тәрбия ала, вакытларын файдалы итеп үткәрә", - дип уртаклашты алар фикерләре белән. Әйтик, оныгы чыгышын карарга килгән Сания апа: "Лагерьга бик теләп йөрде, Коръән сүрәләрен оныгым белән бергә мин дә ятладым", - дип куанычын белдерде.

Мондый әхлакый һәм дини тәрбия чаралары лагерь кысаларында гына тукталып калмыйча, дәвамлы булсын иде дип телисе килә. Ни генә дисәк тә, балачактан ук күркәм гадәтләрне күңелгә сеңдерүне кайгыртмасак, соңыннан - балаң буй җитеп, олы кеше булып формалашып беткәч кенә аны акылга утыртырга теләсәң дә, инде соң булырга мөмкин. Бу хакта вакыт инде күптән килеп җитте.

***Рәсемдә: лагерьда ярминкә мизгеле.***

**Зәлия ЛАТЫЙПОВА,**
**КФУның журналистика һәм социология факультеты студенты**

# Мөселман мәгарифе парадигмасында

**Һичшиксез, дини (мөселман) мәгариф системасы, яңа белем бирү технологияләре кулланып, камилләштерүне көтә. Бу мәсьәлә илебез өчен икеләтә актуаль. Виртуаль университет, дистанцион рәвештә белем бирү, белем дәрәҗәсе һәм уку-укыту барышы буенча тикшерү формасы буларак тестлар эшләүне кертү, балл-рейтинг системасы, укыту-методика комплекслары - болар барысы да ислам мәгарифен модернизацияләү өлкәсенә карый.**

Әмма классик ислам мәгарифе (бигрәк тә ислам фәннәре буенча белгечләр әзерләү) үзенең актуальлеген беркайчан да югалтмады. Безнең көннәрдә кадимчелекне тәнкыйтьләү модага керде. Әмма кадими мәдрәсәләрдә кулланылган төп педагогик алым - балаларны аерым китаплар буенча укыту - бүген дә үзенең әһәмиятен нык сиздерә. Ислам дөньясында сез танылган дин галименнән иҗазәт алмаган бер генә дин әһелен дә таба алмассыз. Ә иҗазәтне аерым китаплар буенча остаз белән индивидуаль рәвештә шөгыльләнеп кенә алырга мөмкин.

Без РИУда электән килгән тәртип-традицияләрне шулай ук яңадан торгызабыз. Инде икенче ел рәттән бездә аерым дәресләрне Пакъстан ислам университетын тәмамлаган егет алып бара. Җәйгә Мароккодан дин галиме Габдрахман Лакримны махсус чакырттык, ул шулай ук студентлар һәм укытучылар белән классик дини әсәрләр буенча дәресләр уздырачак.

Имамнарны идеологик яктан әзерләүгә килгәндә, мин ике аспектны билгеләп узар идем. Беренчедән, Ислам университетын тәмамлаучыларга ихтыяҗ бар. Без нигездә Үзәк Россия мәчетләре өчен имамнар әзерлибез, РИУга илебезнең 45 төбәгеннән килеп укыйлар. Безнең төбәктә хәнәфи мәзһәбен тотучылар зур күпчелекне тәшкил итә. Шуңа күрә студентларыбызның хәнәфи мәзһәбен теориядә (тәгълимат буенча) һәм гамәлдә (практикада) өйрәнүләре бик тә табигый.

Икенчедән, без ислам нигезләре буенча белгечләр чыгарабыз һәм шуның өчен алар исламның бар идеологик спектрын үзләштерергә тиешләр. Ә Россиянең мөселман өммәтендә ниләр барганы, чыннан да, бик катлаулы һәм авыр процесс. Кыска гына итеп, моны үсеш чире дип атарга мөмкин. Бу процессларның нәтиҗәсе турында оптимистик рухта сүз алып барырга бүген бары тик дилетантлар - гадәттә фән яки




сәнгать белән тирән белемнәргә ия булмыйча шөгыльләнүчеләр генә батырчылык итәр.

Студентлар укый торган дәреслекләр буенча эш шактый катлаулы. Югары уку йортлары өчен ислам дине нигезләре буенча рус телендә нәшер ителгән дәреслекләр бик аз. Дөньяви фән тармаклары буенча исламча специальләшкән дәреслекләр бөтенләй юк диярлек. Иҗтимагый дисциплиналар буенча язылган барлык дәреслекләрдә дә Көнбатыш җыры җырлана һәм аларда европоцентризм билгеләре ярылып ята. Политология, социология, хәтта фәлсәфә (философия) буенча да ислам компоненты тәкъдим ителгән дәреслекләрне табуы кыен. Политологиягә караган заманча дәреслекләр буенча безнең студентларны укыту бик үк килешеп бетмәс. Чөнки аларда Ислам һәм мөселман дәүләтләре бары тик тоталитар режимлы һәм теократик системаны тасвирлау өчен генә телгә алына. Ә менә философия буенча чыккан сиксән процент дәреслекләрдә гарәп-мөселман фәлсәфәсе турында бөтенләй әйтелми. Шуңа күрә бу дәреслекләрне безгә йә үзебезгә язарга, йә тәрҗемә итәргә кирәк. Без шуның белән шөгыльләнәбез дә.

Исламны тирәнтен өйрәнү буенча Федераль программа кысаларында без 2007 елдан башлап Казан вузларында эшли торган укытучылар белән бергәлектә сиксәннән артык дәреслек, уку ярдәмлеге, хрестоматия әзерләгән идек. Аларның эчтәлек һәм методик дәрәҗәсе уртачадан түбәнрәк. Әмма иң мөһиме - аларның булуы һәм үзебезнең мөгаллимнәр тарафыннан эшләнүе. Бу - тулы кыйммәтле, сыйфатлы дәреслекләр әзерләү эшенә тотынуда беренче адым. Шулай ук гакыйдә, гаилә һәм мирас хокукы һ. б. буенча федераль дәрәҗәдә кулланыла торган дәреслекләр дә бар.

Россия ислам университеты үз канаты астына ике югары уку йортын ала дисәк тә хата булмас: тулаем дини генә булган вуз һәм дәүләти булмаган, мөселман яшьләрен дөньяви белгечләр буенча әзерләүче уку йорты. Ислам фәннәре факультетына бары тик башлангыч һәм урта дини белеме булганнарны гына, ә анысы булмаган очракта - әзерлек бүлеге аша кабул итәбез. Теология, икътисад (экономика), тел гыйлеме (лингвистика), журналистика белгечлекләре буенча дәүләт дипломнары биргәнлектән, катгый рәвештә бары РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы Кагыйдәләре (беренче чиратта, БДИ нәтиҗәләре) буенча гына кабул итәбез.

**(Ахыры 4 нче биттә.)**

## Казанда намаз вакытлары

| КӨН ИСЕМЕ | ДАТА | СӘХӘР ТӘМАМЛАНА | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | КОЯШ ЧЫГУ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ | ЯСТҮ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *ШИМБӘ* | 21.07.12 | 2:29 | 2:59 | 4:29 | 13:02 | 18:27 | 21:09 | 22:39 |
| *ЯКШӘМБЕ* | 22.07.12 | 2:31 | 3:01 | 4:31 | 13:02 | 18:26 | 21:08 | 22:38 |
| *ДҮШӘМБЕ* | 23.07.12 | 2:33 | 3:03 | 4:33 | 13:02 | 18:25 | 21:06 | 22:36 |
| *СИШӘМБЕ* | 24.07.12 | 2:34 | 3:04 | 4:34 | 13:02 | 18:23 | 21:04 | 22:34 |
| *ЧӘРШӘМБЕ* | 25.07.12 | 2:36 | 3:06 | 4:36 | 13:02 | 18:23 | 21:03 | 22:33 |
| *ПӘНҖЕШӘМБЕ* | 26.07.12 | 2:38 | 3:08 | 4:38 | 13:02 | 18:21 | 21:01 | 22:31 |
| *ҖОМГА* | 27.07.12 | 2:40 | 3:10 | 4:40 | 13:02 | 18:20 | 20:59 | 22:29 |
| *ШИМБӘ* | 28.07.12 | 2:41 | 3:11 | 4:41 | 13:02 | 18:19 | 20:57 | 22:27 |




# "РАМАЗАН – мәрхәмәт ае" акциясе башланды

**Тормыш юлында адәм баласы нинди генә сынауларга-кыенлыкларга тарымый?! Кемнәрдер уйламаганда-көтмәгәндә якыннарын, башка берәүләр исә саулыкларын югалта һәм кеше кулына кала. Якты дөньяга аваз салганнан бирле тәпи атлап китә алмаганнар яки бары тик коляскалар ярдәмендә генә хәрәкәтләнүчеләр дә бар...**

Белгәнебезчә, Казанда гына түгел, республикабызның күп районнарында ярдәмгә мохтаҗ ятимнәр, авыру балалар йортлары эшләп килә. Аллага шөкер, аларның тормышларын аз гына булса да җиңеләйтергә омтылучы, көннәрен яктырак итәргә тырышучы мәрхәмәтле җаннар бар.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге "Болгар" радиосы белән берлектә менә шундый, кеше кайгысына, авырлыкларына битараф булмаганнар катнашында күп сандагы акцияләр үткәреп килә. Күптән түгел Крымсктагы су басулардан зыян күрүчеләргә ярдәм итү максатыннан оештырылган республикакүләм акциягә дә үз өлешен кертте ул.

20 июльдән исә рамазан ае дәвамында алып барылачак "Рамазан - мәрхәмәт ае" дип аталган яңа хәйрия акциясе башланып китә. Әлеге чара республика балалар йортларында тәрбияләнүчеләр өчен спорт инвентарьлары җыю өчен махсус оештырыла. Спорт инвентарьлары дигәндә, һәр сабый өчен зур бүләк булырдай чаңгы, чана, велосипед, туп, скакалка һ. б. спорт уеннары өчен кирәкле әйберләр турында сүз бара. Алар, бер яктан, бала сәламәтлеген ныгытса, икенчедән, бик күп күңелле мизгелләр бүләк итә ала.

Хәдистә әйтелгәнчә, "Безнең ишеккә каккан һәрбер мохтаҗ - Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән бүләк һәм тагын бер яхшы гамәл кылырга бирелгән мөмкинлек". Изге рамазан аенда игелеклесаваплы гамәлләребезне кылырга ашыгыйк!

**Элемтәләр өчен телефон:**
**+7 (843) 264-61-58**
**(Гөлнара Садыйкова)**




# Мөселман мәгарифе парадигмасында

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Безгә укырга кемнәр килә соң? Тулысынча төрле контингент: ихластан дини һәм дөньяви белем алырга теләүчеләр, һәм ахырдан билгеле булганча, армиядән качып йөрүчеләр, элеккеге "өч"ле һәм "биш"ле капчыклары... Дөресен әйтәм, безгә, иң яшь югары уку йорты буларак, КФУ һәм башка дәүләт вузлары белән үзара көрәш алып баруы шактый авыр. Әмма без югары белем бирү системасында һәрдаим үз урыныбызны таба киләбез.

Быелгысы елны РИУда кабул итү планы, читтән торып укучыларны һәм югарыда телгә алынган белгечлекләр буенча дистанцион рәвештә белем алучы төркемнәрне дә кертеп, 300 кешедән гыйбарәт. Вуз дәүләти булмаганлыктан, бездә коммерция һәм бюджет урыннары дигән төшенчә моңа кадәр булмады. Ләкин без уку-укыту процессын, "икътисад" белгечлегеннән тыш, бөтенләй бушка диярлек алып барабыз. Быел без, ислам вузлары тарихында беренчеләрдән булып, бюджет урыннары бүлеп бирелә торган конкурста катнаштык һәм безгә РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тел гыйлеме буенча 10 урын алу насыйп булды. Шулай итеп бюджет урыннары да хасил булды.


Ислам фәннәре факультеты программасын без үзебез раслыйбыз: ул зур мәчетләр өчен имамнар һәм урта мөселман уку йортларында эшләүче дин әһелләре әзерләүгә исәпләнгән. Ә теология факультеты - дәүләт стандартлары буенча эшли һәм шунлыктан без катгый рәвештә әлеге стандартларга буйсынабыз. Дөрес, хәзер инде өченче буын программалар эшләнеп ята, шуңа күрә без яңа мәгариф программалары барлыкка килүдә актив катнашабыз. Студентлар өлгерә аламы соң дигәндә, бездә дә башкалардагы кебек - төрле студентлар бар. Начар өлгереш аркасында вуздан куылу очраклары да күзәтелә. Мисал өчен, әзерлек бүлегенә без 50 тыңлаучы кабул итәбез, ә беренче курска шуның бары тик 15-20 се генә керә. Башка юнәлешләр буенча ситуация күпкә яхшырак, әмма студентларның 20 процентка якыны төрле сәбәпләр буенча укуын ташлый. Өметле күренгәннәрне исә бездә магистратура көтеп тора. Быел без, ислам вузлары арасында беренчеләрдән булып, биш магистрант чыгардык. Аларның магистр эшләре бик тә тирән эчтәлекле. Икесенеке хәтта кандидатлык диссертацияләре дәрәҗәсендә язылган.

Бездә техник мөмкинлекләр алай ук алга киткән димәс идем. Ләкин быел без Дистанцион белем бирү үзәген сафка бастыра алдык. Моның өчен техник мөмкинлекләребез җитә. Югары уку йортыбыз кысаларында Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең бар киңлекләре өчен Ислам дөньясы университетлары федерациясе (ФУИМ) тарафыннан эшләнгән виртуаль вуз программасы сынау үтә. Киләсе елның гыйнвар аеннан башлап, Иншә Аллаһ, Россиядә һәм БДБда беренчеләрдән булып, ислам икътисадыннан дистанцион белем бирү буенча Исламча үсеш банкы белән бергәлектә халыкара проект башлаячакбыз. Дөрес, башта бу инглиз телле версия булачак.

Ә Коръән өйрәнүгә килгәндә исә бездә инде ике ел рәттән онлайн курслар эшләп килә, студент кызлар Эр-Рияд аша үзләренең укытучылары белән турыдан-туры аралашалар. Сүз уңае белән шунысын да әйтү урынлы булыр: быел Коръәнне яттан өйрәнү үзәген Изге Китапны хәтердән укый алучы беренче кызыбыз тәмамлый. Аның исеме газета укучыларыбызга да билгеле булсын - Мәрьям Ганиева. (Ул Экология һәм география институтында (КФУ) да читтән торып белем ала.) Укуын тәмамлаганнан соң Мәрьям бездә эшләргә калыр дип өметләнәбез.

Фото ***www.islam-portal.ru сайтыннан алынды.***

**Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН,**
**сәясәт фәннәре докторы,**
**Россия ислам университеты ректоры**




**ООО «Ритуальные услуги»**
**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница -
с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 225-28-90, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 3 (146) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9408.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 19 июль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклангыз!**